РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 30, Азнакаевский район,
п.Победа, 423312,
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 30 йорт, Азнакай районы, Җиңү
бистәсе, 423312
тел./факс (885592)42-1-38
E-mail: Vahit.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«27» сентябрь 2023 ел** **№ 6**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Җиңү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Уставының 15.1 ст. нигезендә Азнакай муниципаль районының «Вахит авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авылы җирлеге Җиңү торак пунктында Татарстан урамы 1-10 йортлар, Үзәк тыкрык урамы 1-3 йорт, Үзәк урам 1А йорттан алып 13 нче йортка, Үзәк урам 1А -13, 5 нче фатир, Үзәк урам буенча 1А йорттан алып 13 йортның 5 нче фатирны кертеп, Үзәк урам буенча 13 йорттан 6 фатирдан алып 37 йортка кадәр сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 20 октябрендә 9 сәгать 00 минутка беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авылы җирлеге Җиңү торак пунктында Кибет урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр, Яшел урам 59 йорттан 89 йортка кадәр, Яшел урам 50 йорттан 70 йортка кадәр, Үзәк урам 40 йорттан 1 һәм 2 фатирларны кертеп, Үзәк урам 41 йорттан 47 йортка кадәр сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 20 октябрендә 10 сәгать 00 минутка икенче этабын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авылы җирлеге Җиңү торак пунктында Яшьләр урамы 1 йорттан 16 йортка кадәр, Яшел урам 1 йорттан 57 йортка кадәр, Яшел урам 4 йорттан 48 йортка кадәр сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык

җыенын 2023 елның 20 октябрендә 11 сәгать 00 минутка өченче этабын билгеләргә.

4.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегенең Җиңү торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлегенең Башкарма комитетын;

гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты - 2023 елның 20 октябрендә 9.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;

-гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Җиңү торак пункты мәдәният йорты бинасы: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Җиңү торак пункты, Үзәк ур., 29 йорт.

- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты - 2023 елның 20 октябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Җиңү п., Үзәк ур., 29 йорт.

- гражданнар җыенының өченче этабын үткәрү вакыты - 2023 елның 20 октябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;

- халык җыенының өченче этабын үткәрү урыны – Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Җиңү п., Үзәк ур., 29 йорт.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:

"Сез 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

1) Җиңү торак пунктында урамнарны яктыртуны карау һәм аларга хезмәт күрсәтү, яктырту челтәрләрен ремонтлау;

2) Җиңү торак пунктында рус һәм татар зираты территориясен төзекләндерү, киртәләр урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

3) Җиңү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4) халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү, аларга якын урнашкан Җиңү торак пунктын төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Вахит авылы җирлегенең Җиңү торак пунктының Үзәк урам, 30 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районының
Вахит авыл җирлеге башлыгы Г.И. Әскәрова